РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА БОГДАШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

БОГДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

Рус Богдашкиносы ав.

КАРАР

«26» октябрь 2020 ел

№ 1

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге ке Рус Богдашкиносы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегенең Рус Богдашкиносы авылында Чапаев, Гагарин, Бауман урамнарында, Совет урамындагы 40-54,43-65 йортларда, Мәктәп урамындагы 16-34 йортларда, Мәктәп тыкрыгында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын уздыруны 2020 елның 6 ноябрендә Совет урамы, 43 нчы йорт янында 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегенең Рус Богдашкиносы авылында Мәктәп урамындагы 2-14 йортта, Совет урамындагы 2-36, 1-35 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын уздыруны 2020 елның 6 ноябрендә Совет урамы, 17 нчы йорт янында 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегенең Рус Богдашкиносы авылында Пушкин, Тукай, Фрунзе, Октябрьский урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының өченче этабын уздыруны 2020 елның 6 ноябрендә Октябрь урамы, 48 нче йорт янында 12 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Рус Богдашкиносы авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлү тәртибен территориаль билгеләнеш буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.

6. У Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

7. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлегенең Рус Богдашкиносы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, 2 гр инвалидларыннан тыш(I һәм II дәрәҗә хезмәт эшчәнлегенә сәләте чикләнгән очракта), балачактан инвалид булганнардан, көндезге уку формасы буенча укучы

студентлардан тыш, 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Рус Богдашкино авыл җирлеге торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм вак таш һәм грунт катнашмасы салу (сатып алу, ташу, җәю);

Урам утларын ремонтлау һәм карап тоту (кирәкле материал сатып алу, яктырту җиһазларын урнаштыру буенча электромонтаж эшләре);

Зиратны төзекләндерү (хуҗалык блогын ремонтлау, килешү буенча башкарылган эшләр өчен түләү).

« РИЗА» «КАРШЫ».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Богдашкино авыл җирлеге башлыгы А.Л. Михайлова